**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Түбән Ләшәү авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Түбән Ләшәү авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Түбән Ләшәү авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, өлкән, ялгыз яшәүче затлардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Түбән Ләшәү авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);
2) Түбән Ләшәү авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
3) Түбән Ләшәү авылы урамнарын кардан чистарту, карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
4) Түбән Ләшәү авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;
5) “Сарман” район газетасында некролог бастыру;
6) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен бензокосилкага ГСМ алу;
7) Түбән Ләшәү авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);

3. Әлеге карарны Ләшәү Тамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин